# Токмач кисәм.

1. Токмач басып, кисәргә
Мин әнидән өйрәндем,
Бер дә авыр түгел икән,
Кирәк бары теләгең.

Кушымта: Башыма яулык ябынам,
Алъяпкыч салам алга,
Кулларны юып алам да,
Тотынам мин камырга.
Шулпага бераз тоз салам,
Йомырка сытам туглап.
Он салып, камыр басам да,
Калдырам өстен каплап.

2. Ял иттергәч камырымны,
Түгәрәкләп җәямен.
Куна тактасы өстендә
Җәймәмне киптерәмен.

Кушымта: Бер-берсе өстенә куям
Теленгән тасмаларны.
Нечкә, нәзек токмач итеп,
һәм кисәм мин аларны.
Яңа кискән токмач белән
Бик тә тәмле була аш.
Куңелле: "Ярдәмчем!",- диеп,
Әни дә мактап торгач.

Башыма яулык ябынам,

Алъяпкыч салам алга.

Көндә кирәк әниләргә

Шулай гел булышырга.